| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.06.2022 Олы Кайбыч ав. № 277

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 апрелендәге 212 номерлы карары белән расланган «2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, сәламәт яшәү рәвеше алып бару өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы халкына шартлар тудыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 15 февралендәге 244-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасына чаралар планын, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасын финанслау срокларын һәм чыганакларын үзгәртеп, 2020-2025 елларга кушымта итеп бирелә торган яңа редакциядә үзгәрешләр кертергә.

2.Финанс-бюджет палатасында тиешле елга бюджет формалаштырганда Программаны гамәлгә ашыруга район бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып финанс чаралары бүлеп бирүне күздә тотарга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А. Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022е. “16” июнендәге
277 номерлы карарына кушымта

## 2020-2025 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасының чаралар планы, финанслау сроклары һәм чыганаклары

| т/б № | Чараның атамасы | Үтәү вакыты (еллар) | Финанслау чыганаклары (мең сум.) | | | Башкаручылар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | муниц. бюджет | бюджеттан тыш чыганак | барлыгы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| **1. Физик культура һәм спортны үстерү, халыкта сәламәт яшәү рәвеше принципларын формалаштыру буенча оештыру чаралары** | | | | | | |
| 1.1. | Хезмәт коллективларында, ведомство карамагындагы учреждениеләрдә һәм оешмаларда сәламәт яшәү рәвеше өчен хәрәкәт формалаштыру:<br>- яшьләр хәрәкәте үсеше;<br>- иҗтимагый берләшмәләрне үстерү. | ел саен | - | - | - | Районның авыл хуҗалыгы һәм житештерү предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре (килешү буенча), иҗтимагый хәрәкәтләр (килешү буенча) |
| 1.2. | Халыкны сәламәтләндерү һәм физик тәрбия системасын камилләштерү буенча тикшеренүләр үткәрү | 2020-2025 еллар | - | - | - | Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт секторы; «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3. | Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карарлары нигезендә түбәндәге мәсьәләләр буенча район Башлыгы һәм Башкарма комитет җитәкчесе карарлары һәм боерыклары проектларын әзерләргә:<br>- 18 яшьтән яшьрәк затларга алкогольле һәм тәмәке эшләнмәләрен сатуны чикләү;<br>- наркотик чараларны явыз ният белән куллануга һәм аларның законсыз әйләнешенә каршы тору буенча;<br>- балалар һәм яшьләрнең ялын һәм мәшгульлеген, аланы сәламәтләндерүне оештыру буенча киңәшмә;<br>- профессиональ спортчыларга ярдәм итү буенча. | 2020-2025 еллар | - | - | - | Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт секторы; «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 1.4. | Гомуми белем бирү мәктәпләрендә озынайтылган укыту көне һәм тирәнтен укыту-тренировка процессы белән спорт төрләре буенча махсуслаштырылган класслар турында нигезләмәне эшләү һәм гамәлгә кертү | 2025 елга кадәр | - | - | - | Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт секторы (алга таба - ЯСФКһС секторы); «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 1.5. | Массакүләм физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләрен эш бирүчеләр һәм профсоюз комитетлары арасында күмәк шартнамәләргә кертү | ел саен | - | - | - | Район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 1.6. | Ирешелгән нәтиҗәләр өчен аерым спортчыларның һәм җыелма командаларның республика спорт ярышларында катнашуына максатчан ярдәм күрсәтү турындагы нигезләмәне эшләү һәм гамәлгә кертү. | 2021 елга кадәр | - | - | - | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының ЯСФКһС секторы |
| **2. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга һәм укучы яшьләргә физик тәрбия** | | | | | | |
| 2.1. | Мәктәпкәчә белем бирү һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә матди-техник базаны үстерү. | 2020-2025 еллар | 50 | 100 | 150 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, ЯСФКһС секторы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | Физик культура һәм спорт мәсьәләләре буенча гомуми белем бирү мәктәпләре укытучыларының квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү | 2020-2025 еллар | 50 | - | 50 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 2.3. | Укучыларның сәламәтлеге торышын комплексლы мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру:<br>- укучының сәламәтлеге торышы турында мәгълүматлар базасы булдыру (сәламәтлек паспорты);<br>- дәресләрдә сәламәтлек саклау технологияләре кертү. | 2020-2025 еллар | - | - | - | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 2.4. | Мәктәп укучылары өчен профилактик, сәламәтләндерү һәм коррекция чаралары оештыру:<br>- хокук бозуларны, тәмәке тартуны, алкогольле эчемлекләр эчүне профилактикалау һ. б.;<br>- мәктәп укучыларында күрү сәләтен профилактикалау буенча эш;<br>- белем бирүнең барлык баскычларында сәламәтлек көннәре, спорт ярышлары һәм бәйрәмнәр уздыру;<br>- дәресләрдә һәм тәнәфесләрдә физкультура паузалары үткәрү. | 2020-2025 еллар | 60 | 10 | 70 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 2.5. | Районның гомуми белем бирү мәктәпләре арасында физкультура олимпиадалары, спорт бәйрәмнәре, ярышлар, спартакиадалар оештыру һәм үткәрү. | 2020-2025 еллар | 360 | 40 | 400 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, ЯСФКһС секторы |
| 2.6. | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның физик үсеше торышына мониторинг үткәрү. | 2020-2025 еллар | - | - | - | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, ЯСФКһС секторы |
| 2.7. | Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә спортның уен төрләрен үстерү, шул исәптән: «КЭС-БАСКЕТ» мәктәп баскетбол лигасы һәм «Мәктәп волейбол лигасы» ярышлары уздыру. | 2020-2025 еллар | 60 | - | 60 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ, ЯСФКһС секторы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.8. | Район укучылары арасында ГТО нормалары кабул итү | 2020-2025 еллар | 60 | - | 60 | ЯСФКhС секторы, «КМР Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| 2.9. | Районда иң популяр спорт төрләре буенча район ярышлары уздыру | ел саен | 250 | | 250 | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 2.10 | Кайбыч муниципаль районы спортчыларын республика hәм башка ярышларда әзерләү hәм катнашуны тәэмин итү | 2020-2025 еллар | 350 | | 350 | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 2.11 | Эчке эшләр органнарында учетта торучы балигъ булмаганнарны спорт секцияләрендә hәм түркемнәрендә шөгыльләнүгә җәлеп итү | ел саен | - | - | - | ЯСФКhС секторы РЭЭБ белән берлектә (килешү буенча), КДН, профилактиканың башка катнашучылары белән берлектә (килешү буенча) |
| 2.12 | Укучылар арасында спорт-массакүләм hәм сәламәтләндерү эшен оештыру буенча алдынгы тәҗрибәне өйрәнү hәм гамәлгә кертү | ел саен | - | - | - | «Мәгариф бүлеге« МКУ, КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 2.13 | Яшь спортчылар өчен җәйге спорт-сәламәтләндерү лагере оештыру hәм уздыру | 2020-2025 еллар | 350 | 50 | 400 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" МКУ, ЯСФКhС секторы |
| 2.14 | Гомуми белем бирү учреждениеләрен кирәкле спорт инвентаре hәм җиhазлар белән тәэмин итү | ел саен | 100 | 50 | 150 | «Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ |
| **3. Хезмәт халкын hәм өлкән яшьтәге гражданнарны физик тәрбияләү** | | | | | | |
| 3.1. | Хезмәт hәм ялны оештыру системасына физик культураны hәм спортны кертү | 2020-2025 еллар | 10 | - | 10 | Районның авыл хуҗалыгы җитештерү предприятиеләре, оешмалары hәм учреждениеләре коллективлары (килешү буенча) |
| 3.2. | Район халкының барлык категорияләре тарафыннан ГТО нормаларын тапшыру | 2020-2025 еллар | 60 | - | 60 | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3. | Спорт мәйданчыкларында һәм авыл җирлекләре территорияләрендә массакүләм ял итү урыннарында спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру | 2024 елга кадәр | 30 | 30 | 60 | Районның авыл җирлекләре (килешү буенча) |
| 3.4. | Предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт-массакүләм эшен иң яхшы куелышына смотр-конкурслар үткәрүне оештыру | 2020-2025 еллар | 30 | - | 30 | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 3.5. | Халык арасында хокук бозуларны, алкоголизмны, тәмәке тартуны һәм наркоманияне профилактикалау эшен оештыру | 2020-2025 еллар | 20 | 20 | 40 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районындагы бүлекчәсе (килешү буенча), ЯСФКhС секторы, Кайбыч МР Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| 3.6. | Авыл җирлекләре территорияләрендә «Сәламәтлек көннәре», спорт бәйрәмнәре үткәрү | 2020-2025 еллар | - | 20 | 20 | районның авыл җирлекләре (килешү буенча), ЯСФКhС секторы |
| 3.7. | Хезмәт коллективлары һәм авыл җирлекләре ир-атлар һәм хатын-кызлар командалары арасында волейбол буенча район даими чемпионатын уздыру | ел саен | 400 | - | 400 | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 3.8. | «Россия чаңгы юллары», «Милләтләр кроссы» традицион массакүләм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү | ел саен | 50 | - | 50 | ЯСФКhС секторы, КМР Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| 3.9. | Спорт төрләре буенча спорт федерацияләре төзү | 2020-2025 еллар | - | - | - | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 3.10 | Район, оешма, учреждениеләрдә, авыл хуҗалыгы һәм җитештерү предприятиеләрендә физик культура инструктор-методистлары штаты кертү | 2020-2025 еллар | - | 100 | 100 | Район учреждениеләре, авыл хуҗалыгы һәм җитештерү предприятиеләре җитәкчеләре (килешү буенча) |
| 3.11 | Төрле спорт төрләре буенча ветераннар арасында ярышлар оештыру | ел саен | 30 | 30 | 60 | ЯСФКhС секторы, Кайбыч МР социаль яклау бүлеге (килешү буенча) |
| **4. Инвалидлар арасында физик культура һәм спорт** | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1. | Инвалидлар өчен спорт учреждениеләрендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен кирәкле шартлар тудыру | 2020-2025 еллар | 30 | 10 | 40 | Район Советы (килешү буенча) һәм Башкарма комитет |
| 4.2. | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар өчен спартакиадалар үткәрү | ел саен | 30 | - | 30 | ЯСФКhС секторы, социаль яклау бүлеге (килешү буенча) |
| 4.3. | Өйдә белем алучы инвалид балалар өчен өйдә реабилитация чаралары оештыру | 2020-2025 еллар | 10 | - | 10 | ЯСФКhС секторы, социаль яклау бүлеге (килешү буенча) |
| **5. Милли, техник, гамәли спорт төрләрен үстерү** | | | | | | |
| 5.1. | Милли, техник, гамәли спорт төрләрен үстерү өчен шартлар тудыру, аларны заманча физик тәрбия системасына кертү | 2020-2025 еллар | 20 | - | 20 | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 5.2 | Спорт төрләрен үстерү:<br>-йөзү;<br>-көрәш;<br>-бадминтон | 2020-2025 еллар | - | - | - | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы, спорт төрләре буенча федерацияләр |
| **6. Спорт төрләре буенча федерацияләр эшен оештыру һәм камилләштерү** | | | | | | |
| 6.1 | Спорт төрләре буенча федерацияләр төзү | 2020-2025 еллар | - | - | - | КМР Башкарма комитетының ЯСФКhС секторы |
| 6.2 | Россия Федерациясенең иҗтимагый эшчәнлеге турында нигезләмәләрне эшләү | 2020-2025 еллар | - | - | - | Спорт төрләре буенча федерация (килешү буенча) |
| 6.3 | Спорт төрләре буенча федерацияләр утырышларын уздыру, планнар кабул итү һәм нәтиҗәләр ясау | квартал саен | - | - | - | Спорт төрләре буенча федерация (килешү буенча) |
| **7. Матди-техник базаны үстерү** | | | | | | |
| 7.1 | Авыл җирлекләре территорияләрендә уен мәйданчыклары, йөгерү юллары, чаңгы трассалары планлаштыру һәм төзү | 2020-2025 еллар | - | 40 | 40 | Кайбыч районы Башкарма комитеты, авыл җирлекләре (килешү буенча) |
| 7.2 | Олы Кайбыч авылында чаңгы трассасын модернизацияләү (тренировка трассасы) | 2020-2025 еллар | 50 | - | 50 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.3 | Булган спорт мәйданчыкларын реконструкцияләү һәм яңарту, гомуми белем бирү мәктәпләренең спорт залларын спорт җиһазлары белән җиһазлау | 2020-2025 еллар | 30 | - | 30 | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **8. Мәгълүмат-пропаганда эше** | | | | | | |
| 8.1. | « Кайбыч таңнары» - «Кайбицкие зори» район газетасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау | 2020-2025 еллар | - | - | - | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Кайбыч таңнары» - «Кайбицкие зори» район газетасы редакциясе |
| 8.2. | Физкультура-спорт оешмаларында физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү мөмкинлекләре турында халыкка мәгълүмат бирү буенча районның рәсми сайтында бүлек булдыру һәм урнаштыру | 2020-2025 еллар | - | - | - | Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының ЯСФКһС секторы |
| 8.3. | Сәламәт яшәү рәвеше буенча стендлар, мәгълүмати бюллетеньнәр рәсмиләштерү | 2020-2025 еллар | 10 | - | 10 | Авыл җирлекләре, районның җитештерү предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре (килешү буенча) |
| 8.4. | Районның спорт объектлары, секцияләр исемнәре һәм тренерлар ф.и.а. күрсәтеп, «спорт картасы»н булдыру. | 2022 елга кадәр | - | - | - | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының ЯСФКһС секторы |
| 8.5. | «Спорт резервы» мәгълүмат базасы булдыру | 2022 елга кадәр | - | - | - | Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының ЯСФКһС секторы |